| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ЧЕРЕМШАНСКИЙ<br>МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН<br>**СОВЕТ ЛАШМАНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**<br><br>ул.Советская дом 55А, село Лашманка, 423110 | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>**ЛАШМАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ**<br><br>Советлар урамы,55А йорт, Лашман авылы, 423110 |
| --- | --- | --- |

тел./факс +7(84396) 2-92-35 email: Lash.Cmn2@tatar.ru

**№ 143** **05 март 2025 ел**

**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районының**
**Лашман авыл җирлеге Советы**
**карары**

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Лашман авыл җирлеге Советының
2012 елның 29 декабрендәге
«Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Лашман авыл җирлегенең җирдән
файдалану һәм төзелеш
кагыйдәләрен раслау турында»
№ 58 карарына үзгәрешләр
кертү хакында

«Россия Федерациясе Җир кодексына, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Россия Федерациясе Җир кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 5 статьясындагы 2 өлешенең үз көчен югалтуын тану хакында» 2024 елның 26 декабрендәге № 485-ФЗ Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Лашман авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Лашман авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Лашман авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 27 декабрендәге 26 номерлы карарына (Лашман авыл җирлеге Советының 2018 елның 30 декабрендәге 112 номерлы;2021 елның 16 июнендәге 28 номерлы; 2021 елның 19 августындагы 30 номерлы; 2022 елның 18 маендагы 54 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.1 пунктның 2,3 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә: «Автомобиль юлының юл буе полосалары - беренче, икенче яисә өченче категорияле автомобиль юлына бүленгән полосага ике яктан да якын урнашкан һәм чикләрендә юл хәрәкәте иминлеге

таләпләрен, шулай ук автомобиль юлын реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, ремонтлау, карап тотуның, автомобиль юлының үсеш перспективаларын исәпкә алып, аның сакланышының нормаль шартларын тәэмин итү максатларында җир кишәрлекләреннән (җир кишәрлекләренең өлешләреннән) файдалануның махсус режимы билгеләнә торган территорияләр.

Зона параметрлары һәм зонадагы эшчәнлекне чикләү «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законы нигезендә билгеләнә.

2. Әлеге карарны рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Лашман авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе Р.Г.Фәттахов